ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:
а) егерменче абзацта «кеше сәламәтлегенә» сүзләреннән соң «зарарлы йогынты» сүзләрен өстәргә;
б) егерме алтынчы абзацта «атмосфера һавасы сыйфатының экологик нормативларына» сүзләрен «атмосфера һавасы өчен әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты нормативларына» сүзләренә алмаштырырга;
в) кырык бишенче абзацта «кеше сәламәтлегенә» сүзләреннән соң «аның зарарлы йогынтысын» сүзләрен өстәргә;
г) кырык җиденче абзацта «табигать комплекслары һәм объектлары урнашкан» сүзләрен «табигать комплекслары һәм объектлары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектлары, табигый экологик системалар урнаша торган» сүзләренә алмаштырырга;

2) 83 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«83 статья. **Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда атмосфера һавасын саклау таләпләре**

1. Капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, эксплуатацияләгәндә, сүткәндә атмосфера һавасы сыйфатының гигиена нормативларын һәм атмосфера һавасы өчен әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты нормативларын үтәү тәэмин ителергә тиеш.

2. Капиталь төзелеш объектларын җирлекләр, шәһәр округлары чикләрендә проектлаганда, төзегәндә атмосфера һавасын пычратуның фон дәрәҗәсе, шул исәптән атмосфера һавасы пычрануны җыелма исәпләү нәтиҗәләре буенча алынганы, һәм шушы эшчәнлекне башкарганда аның сыйфаты үзгәрешен фаразлау исәпкә алынырга тиеш.

3. Атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясый ала торган капиталь төзелеш объектларының проектлау документациясендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрне чыгаруларны киметү һәм аларны зарарсызландыру чаралары каралырга тиеш.

4. Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарыла торган капиталь төзелешнең яңа һәм (яисә) реконструкцияләнгән объектларын эксплуатациягә тапшырганда атмосфера һавасына чыгарып ташлауларның, иң чик мөмкин булган чыгарып ташлауларның технологик нормативларын, физик йогынтыларның иң чик мөмкин булган нормативларын арттыру рөхсәт ителми.

5. Атмосфера һавасын саклау кагыйдәләрендә каралган газлар чистарту җайланмалары һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны тикшереп тору чаралары булмаган капиталь төзелеш объектларын төзү, эксплуатацияләү тыела.

6. Эшләүләре климатның һәм атмосфераның озон катламының уңайсыз үзгәрешләренә китерергә, кешеләрнең сәламәтлеге начараюга, үсемлекләрнең генетик фондын һәм хайваннарның генетик фондын юкка чыгаруга китерергә, әйләнә-тирә мохит өчен кире кайтарылмаслык нәтиҗәләр китереп чыгарырга мөмкин булган капиталь төзелеш объектларын проектлау, төзү тыела.»;

3) 85 статьяда:
а) исемендә татарча текст үзгәрешсез кала;
б) 3 өлештә татарча текст үзгәрешсез кала;

4) 87 статьяда:
а) исемендә «зарарлы» сүзен төшереп калдырырга;
б) «зарарлы» сүзен төшереп калдырырга;

5) 90 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«90 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлауларны җайга салу**

Эшчәнлекләре нәтиҗәсендә атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясый торган җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килә торган юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар, куллану процессында атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясый торган калдыклар барлыкка килә торган физик

затлар мондый калдыклар белән «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эш итәргә тиеш.»;

6) 94 статьяның 3 өлешендә «җирләрне сугару һәм ашлау» сүзләрен «сугару һәм башка мелиоратив чараларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга, «санитар законнар» сүзләрен «санитария-эпидемиология таләпләре» сүзләренә алмаштырырга;

7) 95 статьяның 3 өлешендә «Җирләрне агып төшүче сулар белән сугару һәм ашлау» сүзләрен «Сугару һәм башка мелиоратив чараларны гамәлгә ашыру өчен агып төшүче сулардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

8) 96 статьяның 3 өлешендә «мелиоратив эшләр әйләнә-тирә мохитне саклау, су объектларын һәм аларның су җыю мәйданнарын яклау» сүзләрен «мелиоратив чаралар әйләнә-тирә мохитне, су объектларын һәм аларның су җыю мәйданнарын саклау» сүзләренә алмаштырырга;

9) 105 статьяның 4 өлешендә «(зарарлы)» сүзен төшереп калдырырга;

10) 132 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «г» пунктчасы, 6 – 8 һәм 10 пунктлары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан , Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 69-ТРЗ